КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 июль г.Казань № 832

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 1 апрель, 163 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 1 апрель, 163 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 02 декабрь, 838 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында мемориаль такталар кую тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның өченче абзацында татар текстында «мәңгеләштерү» сүзенә кадәр «шәхесләрне» сүзен өстәргә;

1.2 пунктка «һәм даталар» сүзләрен өстәргә;

II бүлекнең исеменә «һәм даталар» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктның икенче абзацында «вакыйганың мөһимлеге» сүзләренә кадәр «датаның һәм» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Вакыйганың тарихи әһәмиятен, датасын яки исемен мәңгеләштерергә тәкъдим ителә торган зат уңышларын, казанышларын объектив бәяләү максатларында мемориаль такта вакыйга булган көннән алып биш елдан да иртәрәк булмаган вакытта һәм исеме мәңгеләштерелергә тиешле затның үлеменнән соң өч елдан да иртәрәк булмаган вакытта куелырга мөмкин.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланганчы Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, шулай ук батырлык күрсәткән, Татарстан Республикасы һәм (яисә) Россия

Федерациясе алдында күренекле казанышлары һәм аерым казанышлары булган, шул исәптән Россия Федерациясе (СССР, РСФСР) һәм Татарстан Республикасы (ТАССР, ТССР) дәүләт бүләкләре белән билгеләп үтелгән башка гражданнар истәлеге мәңгеләштерелергә мөмкин. Мемориаль такта билгеләү турындагы тиешле карар искәрмә тәртибендә мемориаль такта урнаштыру инициаторының (алга таба - инициатор) мотивлаштырылган мөрәҗәгате һәм (яисә) Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Мемориаль librtакталар буенча комиссиянең (алга таба - Комиссия) үтенечнамәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.»;

III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт өстәргә:

«3.3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларында (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрендә) мемориаль такталар урнаштыру (алга таба - мәдәни мирас объектлары) мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге законнарда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен башкару тәртибен үтәп гамәлгә ашырыла.»;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Мемориаль тактаның тышкы күренешенә таләпләр

4.1. Мемориаль такталар бары тик озак вакытлы материаллардан (гранит, бронза, бакыр, алюминий һәм башка металл һәм эретмәләрдән) ясала.

4.2. Мемориаль такта тексты кыска формада бәян ителергә һәм түбәндәге эчтәлектә булырга тиеш:

кулланыла торган телләрнең һәрберсендә 200 дән дә артык булмаган билге (пробелларсыз);

мемориаль такта багышланган вакыйга, дата һәм (яисә) зат (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) һәм (яисә) псевдоним, төп казанышлар хакында белешмәләр) турында мәгълүмат;

мемориаль такта урнаштырылган тәгаен адреслы вакыйга, дата һәм (яисә) затның элемтәсенә күрсәтү.

4.3. Мемориаль такта композициясенә, тексттан тыш, түбәндәгеләр дә кертелергә мөмкин:

скульптур портрет сурәте һәм тематик декор элементлары;

чәчәкләр кую өчен махсус урын яисә җайланма;

яктырту элементлары;

мемориаль тактага багышланган вакыйга, дата һәм (яисә) зат турында өстәмә мәгълүмат белән QR-код.

4.4. Мемориаль такталар әзерләгәндә фотогравировкадан файдалану рөхсәт ителми.

4.5. Мемориаль тактаның төгәл зурлыгы урнаштырылган мәгълүмат күләменнән, сурәт һәм декоратив элементларның булу-булмавыннан, күздә тотыла торган урнаштыру урыны күләменнән чыгып билгеләнә һәм 1 кв.метрдан артмаска тиеш.

4.6. Мемориаль тактаның сәнгать карары аны урнаштыру урынының архитектур үзенчәлекләренә туры килергә тиеш.»;

5.1 пунктта «мемориаль такта урнаштыру (алга таба - инициатор)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2 пунктта:

дүртенче абзацта татар текстында «вакыйганың дөреслеге» сүзләренә кадәр «дата һәм» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мемориаль такталың төсле эскизы, үлчәмнәрне, шрифтларны һәм ул эшләнә торган материалны күрсәтеп; мемориаль такталың М 1:1 йомшак материалында җентекләп эшләнгән сурәт һәм күләмле сурәтләр башкарылган очракта текст белән макеты;»;

җиденче абзацта «биналар,» сүзеннән соң «, корылмалара» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәдәни мирас объектында мемориаль такта урнаштырганда мемориаль такта урнаштыру методы һәм технологиясе тасвирланган проект (бина яисә корылмага күрсәтелә торган йөкләнешнең исәпләрен күрсәтеп, беркетү элементларын һәм фаразланучы беркетүнең тотып тору сәләтен исәпләп).»;

5.3 пунктта «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Мемориаль такталар буенча комиссия (алга таба - Комиссия)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Мемориаль такта кую турында Комиссия уңай карар кабул иткән очракта Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мондый карар кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тиешле карар проектын тапшыра.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелгәнче мемориаль такта кую турындагы карар проекты республиканың кызыксынган башкарма хакимият органнары белән килештерелергә тиеш.

Проектка кушымта итеп бирелә:

Комиссия утырышы беркетмәсе яисә беркетмәсеннән өземтә;

мәңгеләштерелә торган вакыйга, аның датасы һәм (яисә) зат турында гомуми белешмәләр;

мемориаль такта куюның күздә тотылган урыны турында мәгълүмат;

мәдәни мирас объектында мемориаль такта урнаштырганда урнаштыру методы һәм технологиясе тасвирланган мемориаль такта урнаштыру проекты;

мемориаль тактаны проектлау, әзерләү һәм билгеләү эшләрен финанслау чыганаклары турында белешмәләр;

территориясендә мемориаль такта урнаштыру тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы килештерүе.

Комиссия тарафыннан тискәре карар кабул ителгән очракта, инициаторга бу хакта мондый карар кабул ителгән көннән соң 15 көн эчендә хәбәр ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин